**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» январь 2020 с. Тюлячи № 20

Теләче муниципаль районы территориясендә «Торак - 2020» күзәтү-профилактика операциясе үткәрү турында

Россия Эчке эшләр министрлыгының БИ ПР һәм КЭИ Татарстан Республикасы буенча РКЭБ һәм ПР Саба һәм Теләче районнары буенча баш инспекторының 2020 елның 17 гыйнварындагы 10 номерлы хатын карап, “Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, торак фондта янгыннарны һәм аларда кешеләрнең үлемен кисәтү максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районында «Торак-2020» күзәтү - профилактика операциясе үткәрергә.
2. «Торак - 2020» операциясен әзерләү һәм үткәрү планын расларга, 1 номерлы кушымта нигезендә.
3. Теләче муниципаль районы территориясендә торак секторны тикшерү буенча профилактик чаралар үткәрү өчен 13 профилактик төркем составын расларга, 2 номерлы кушымта нигезендә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И. Х. Хәмидуллинга йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов

1 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
белән расланды
«___» _______ 2020 ел № _____

# ПЛАН
## «Торак-2020» операциясен әзерләү һәм үткәрү буенча

| № т/б | Чаралар исеме | Үтәү срогы | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1. | Район «Теләче» (Тюлячи) газетасында «Торак - 2020» операциясен үткәрү турында бастырып чыгарырга | әлеге көнгә кадәр 01.02.2020 | Районара күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге (алга таба текст буенча-РКЭБ) (килешү буенча) |
| 2. | Җирле үзидарә органнары, эчке эшләр органнары, социаль яклау органнары, электр челтәрләре, газ хезмәте һәм башка күзәтчелек органнары вәкилләре белән берлектә күп балалы гаиләләрнең һәм ялгыз яшәүче гражданнарның, социаль яктан имин булмаган катламнарның, спиртлы эчемлекләр һәм наркотиклардан файдаланучыларның яшәү урыннарын, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларын, халыкны һәм җәмәгатьчелекне җәлеп итеп, билгеле бер яшәү урыны булмаган затларны тикшерү һәм әлеге даирәдәге кешеләрнең яшәү урыннарында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча тиешле чаралар күрү. Алар белән көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү буенча профилактик әңгәмәләр үткәрергә | Ел дәвамында | РКЭБ, 134 ПСЧ ФДКУ "ТР буенча ФЯХО 7", ТР буенча Олы Нырсы АП БИ, Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлекчәсе, халыкны социаль яклау бүлеге, электр челтәре, газ хезмәте, ӨһБ әгъзалары һәм авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 3. | «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» 2007 ел, 21 нче июль, 185-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру кысаларында торак фондына капиталь ремонт үткәрү буенча муниципаль программаларга янгынга каршы иң имин булмаган күп фатирлы йортларда янгынга каршы чараларны кертү буенча эшне оештырырга; янгынга каршы чараларны үтәү өлешендә аларны тормышка ашыруны һәм аларның сыйфатын контрольдә тотарга | Ел дәвамында | РКЭБ (килешү буенча) |
| 4. | Торак фондының һәм торак пунктларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында, массакүләм мәгълүмат чараларында, | Ел дәвамында | РКЭБ (килешү буенча) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | теле - һәм радиоканалларда үткәрелә торган чараларны һәм проблемалы мәсьәләләрне яктыртуны оештыру. Янгыннар белән оператив хәлләр турында халыкка хәбәр итүне, көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чараларын җиткерүне оештырырга. Янгын куркынычсызлыгы тематикасына агитация һәм пропаганда материаллары (белешмәлекләр, мәгълүмат битләре, тәкъдимнәр) әзерләү буенча җирле үзидарә органнарына методик ярдәм күрсәтергә һәм халык арасында почта элемтәсе, торак оешмалары, халыкны социаль яклау хезмәткәрләре, милициянең участок уполномоченныйлары мөмкинлекләреннән файдаланып таратуны оештырырга | | |
| 5. | Торак фондының һәм торак пунктларның янгынга каршы торышы турындагы мәгълүматны гомумиләштерүне һәм анализлауны оештырырга. Җирле үзидарә органнарына, торак оешмалары җитәкчеләренә торак фондта һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәү турында тәкъдимнәр (күрсәтмәләр) җибәрергә. Үткәрелә торган тикшерүләр турында прокуратура органнарына хәбәр итәргә | Ел дәвамында | РКЭБ (килешү буенча) |
| 6. | Торак фондта һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгы торышы турындагы сорауларны гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча муниципаль комиссияләр утырышларында карарга | Тикшерү нәтиҗәләре буенча | Комиссия әгъзалары, янгыннарның артуы күзәтелгән авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 7. | Инструктажлар журналында кул кую өчен белешмәлекләр биреп, халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтеп, торак пунктларда торак йортларны карап чыгу | Ел дәвамында | РКЭБ, 134 ПСЧ ФДКУ "ТР буенча ФЯХО 7", " ТР буенча Олы Нырсы АП БИ, Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлекчәсе, халыкны социаль яклау бүлеге, электр челтәре, газ хезмәте, ӨҺБ әгъзалары һәм авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 8. | Кешеләр күпләп җыела торган урыннарда «Торакны янгыннан саклагыз» дигән тематик стендлар урнаштырырга, һәрдаим андагы | Ел дәвамында | РКЭБ, 134 ПСЧ ФДКУ "ТР буенча ФЯХО 7", авыл |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | мәгълүматны яңартып торырга | | җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 9. | Торак фондның янгын куркынычсызлыгы торышы һәм кешеләрнең үлемен кисәтү турында экспресс-мәгълүмат эшләү һәм тарату | 25.01.20 алып-31.12.20 кадәр | РКЭБ, 134 ПСЧ ФДКУ " ТР буенча ФЯХО 7», «АП БИ Олы Нырсы ТР буенча», авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 10. | Барлык торак пунктларда гражданнар җыеннары үткәрү, аларда янгыннарны профилактикалау мәсьәләләре буенча фикер алышу | Расланган график буенча | РКЭБ, 134 ПСЧ ФДКУ "ТР буенча ФЯХО 7", авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 11. | Мәктәп укучылары, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре балалары белән очрашулар оештырырга һәм балалар шуклыгыннан янгыннарны кисәтүгә юнәлдерелгән әңгәмәләр үткәрергә | Ел дәвамында | РКЭБ (килешү буенча), РОО |
| 12. | Дин тотучылар арасында янгыннарны профилактикалауда аларны куллану өчен районда һәм республикада булган янгын фактлары буенча дини конфессияләр җитәкчеләре адресына экспресс-мәгълүмат эшләү һәм җибәрү | 25.01.20 алып-31.12.20 кадәр | РКЭБ (килешү буенча) |

2 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
белән расланды
«23» 01 2020 ел № 20

## Теләче муниципаль районы территориясендә торак секторны тикшерү буенча профилактик чаралар үткәрү өчен профилактик төркемнәр составы

| № т/б | Оешма, учреждение, предприятиеләр исеме | Профилактик төркем әгъзалары саны |
|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ баш идарәсенең Саба һәм Теләче МР күзәтчелек эшләр һәм профилактик эшләр районара бүлеге (килешү буенча) | 2 |
| 2. | 134 «ТР буенча 7 ФЯХО» федераль дәүләт казна учреждениесенең янгын-коткару бүлеге (килешү буенча) | 30 |
| 3. | Олы Нырсы авылының «ТР буенча БИ» аерым посты (килешү буенча) | 7 |
| 4. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлекчәсе (килешү буенча) | 4 |
| 5. | «Чишмә» халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге (килешү буенча) | 8 |
| 6. | Авыл җирлекләре башлыклары, ирекле янгын сүндерүчеләр командалары әгъзалары (килешү буенча) | 13 |
| 7. | Профилактик төркемнәрнең гомуми саны | 13 |